**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

26 ноябрь 2021 ел № 2

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Балтач торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнерәк пенсионерлар өчен 150 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертергә

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүг буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:
- Урам яктырткычлары, яктырткычлар ,махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру ,Балтач авылында килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Балтач авылы территориясендә чүп үләннәрен чабу;
- Балт Балтач авылы зираты территориясендә чүп үләннәрен чабу, чүп-чар җыю;
- Балтач авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү,
"Җиңү Көне « Сабантуй», « Өлкәннәр көне»,» Яңа ел"
- Трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу
- Трактор өчен җиһазлар сатып алу ( төягеч, чапкыч)

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Балтач авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Рәис Л.Л.Хәбипов